| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ**
09.02.2026 г.

с. Старое Дрожжаное

**КАРАР**
№ 8/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.11.2019 елның 60/4 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.11.2019 ел, № 60/4 карарына (28.05.2020 ел, № 68/1, 15.11.2022 ел, №26/3, 23.10.2023 ел, № 39/3, 23.09.2024 ел, № 50/1, от 13.12.2024 № 53/3, 14.11.2026 ел №3/2 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **4 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) РФ Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата РФ Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;»;

2) түбәндәге эчтәлекле **4.1 пунктча өстәргә:**

"4.1) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;".

2. Әлеге карарны Иске Чүпрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Иске Чүпрәле авыл җирлеге сайтына урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары

Р.Д.Низамов